


# Әмирхан Еники

## (1909 – 2000)

# Дәүләкән – Дим буендагы гүзәл табигать почмагы



Матурлык һәм ямьсезлек – әдәбиятта мәңгелек темаларның берсе. Әмирхан Еникинең сез укып килгән әсәре дә «Матурлык» дип атала.

Сез ничек уйлыйсыз, нәрсә соң ул матурлык?



1. ***Матурлык – гүзәл, күңелгә рәхәтлек бирә торган нәрсә (күренеш,эш, тормыш һ.б.); матур, сокланырлык урыннар (табигатьтә, матур әдәбият әсәрләрендә).***

2. ***Ягымлы, сөйкемле, үзенә җәлеп итә торган тышкы кыяфәт; кеше характерындагы, эшчәнлегендәге хуплана торган сыйфат.***

"Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"



## Матурлык турында татар халык мәкальләре.

1. ***Матурлык – йөзгә яккан буяу, тик тиз китәр.***
2. ***Матурлык күлмәк белән сәдәптә түгел, оят белән әдәптә.***
3. ***Матурлык туйда кирәк, татулык көн дә кирәк.***
4. ***Тышкы матурлык белән масайма, эчке матурлык белән масай.***
5. ***Матурлыкны эзләмә, күңелгә ятырны эзлә.***
6. ***Матур матур күренмәс, сөйгән матур күренер.***

# Матур кеше нинди сыйфатларга ия була?

**М- …**

**А- …**

**Т- …**

**У- …**

**Р- …**

# Матур кешегә хас сыйфатлар:

**М** – *мәгънәле, миһербанлы*

**а** – *акыллы, аңлы*

**т** – *тыйнак, тәртипле*

**у** – *уңган, укымышлы*

**р** – *риясыз, рәхимле, рухи бай*

# Проза әсәрләрен анализлау тәртибе:

1. Жанры (роман, повесть, новелла, хикәя һ.б.) һәм аны билгеләүче сыйфатлар.
2. Темасы (әсәр нәрсә турында?).
3. Сурәтләү үзенчәлекләре (портрет; пейзаж; интерьер; хикәяләү формасы, ягъни кем исеменнән сөйләнүе һ.б.).
4. Әсәрнең конфликты.
5. Образлар системасы.
6. Сюжеты (сюжет элементлары).
7. Әсәрнең идеясе.
8. Әсәрнең әһәмияте (идея-эстетик кыйммәте, тәрбияви әһәмияте, әдәбиятта тоткан урыны һ.б.).



**Тышкы күркәмлек түгел, бәлки рухи байлык, интеллект, нечкә зәвык, чама хисе һәм яхшы күңеллелек матур итә икән кешене.**

*Ана - бөек исем!*
*Нәрсә җитә Ана булуга.*
*Хатын-кызның бөтен матурлыгы,*
*Бөтен күрке Ана булуда...*




“Әмирхан Еники - күңел карурманнарының тургае”.
Илдар Юзеев
www.topwallpapers.ru

**Өй эше:** «Сезнең өчен ут йотам,

Уйлап карагыз, балам»

(шагыйрь Муса Җәлилнең әнисе Рәхимә Җәлилованың балаларына язган шигъри хатыннан өзек) исемле кыска иҗади инша язып килергә.

Уңышлар сезгә!